ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әтнә муниципаль районы
Күәм авыл
җирлеге Советы

422740, ТР Әтнә муниципаль районы,
Күәм авылы, Х.Такташ урамы, 1/1,тел.3-63-39

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Кубянского
сельского поселения
Атнинского муниципального района

422740, РТ, Атнинский муниципальный район,
село Кубян, улица Х.Такташа, 1/1 тел.3-63-39

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күәм авыл җирлеге Советы

**КАРАР**

«25» июнь 2021 ел № 27

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Советының 2021 елның 9 мартындагы 23 номерлы «Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрләргә һәм пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга бер тапкыр акчалата түләү турында» карарына үзгәрешләр кертү**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Советының 2021 елның 9 мартындагы 23 номерлы «Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрләргә һәм пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга бер тапкыр акчалата түләү турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 1 нче кушымтаның 3 пунктындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә эштән киткәндә ("Иминият пенсияләре турында" 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә җиткәч йә вакытыннан алда картлык буенча иминият пенсиясе яисә инвалидлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгәндә)»;

2) 2 нче кушымтаның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу дигәндә, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 28 статьясындагы 1 өлешендә каралган нигезләр буенча, "Иминият пенсияләре турында" Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә җиткәч йә вакытыннан алда картлык буенча иминият пенсиясен яисә инвалидлык буенча иминият пенсиясен билгеләгәндә һәм тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле муниципаль хезмәт стажы булганда, муниципаль хезмәттән азат ителү аңлашыла».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (http:atnya.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Күәм авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Гатауллин